


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№6 Февраль, 2025 ел*




## Бәйрәмнәрнең иң затлысы

Кышның соңгы бәйрәме-23 февраль, Ватанны саклаучылар көне яки хәрби дан көне. Традиция буенча бу көнне барлык ир-атларны кечедән алып олыга кадәр котлыйлар, чөнки аларның һәркайсы потенциаль яклаучы булып тора. Әгәр дә бәла килеп чыкса, ул гаилә һәм Ватанны яклауга басачак. Бу көнне радио һәм телевидениедән ир-атларга багышланган бәйрәм концертлары трансляцияләнә. Күп кенә гаиләләрдә бәйрәм өстәле әзерлиләр һәм кунаклар чакыралар. Безнең гаилә-искәрмә түгел. Әни белән әби иртәдән үк миңа һәм этигә бүләкләр бирәләр, безне котлыйлар, өйдә тәртип урнаштыралар һәм бик күп тәмле ризыклар әзерлиләр. Бигрәк тә миңа тавык бәлеше ошый – бу безнең бәйрәм өчен традицион ризык. Кич белән безгә этинең абыйсы килә һәм без бәйрәм итәргә утырабыз. Соңрак, бөтенләй караңгы төшкәч, без районга паркка барабыз, анда бәйрәм фейерверкы җибәрәләр.Бу бәйрәм бик мөһим, чөнки ир-атларның төп билгеләнешләренең берсе-үз җиреңне, үз илеңне саклау булып тора һәм ир-атларга, әлбәттә, бу сыйфатны белү рәхәт. Киләчәктә мин дә үз илемне сакларга сүз бирәм, бу биргән сүземдә торырмын дип уйлыйм.

**7 нче сыйныф укучысы Хадиев Салават**

## Әти һәм мин – спорт сөюче гаилә



23 февраль – Ватанны саклаучылар көне уңаеннан мәктәбебездә башлангыч сыйныф укучылары арасында “Әти һәм мин – спорт сөюче гаилә”бәйгесе оештырылды. Анда һәр сыйныфтан бер егет һәм аның этисе катнашты. 1 сыйныфтан – Сабирзяновлар, 2 сыйныфтан – Хасбиуллиннар, 3 сыйныфтан – Эргашовлар, 4 сыйныфтан – Шигаповлар гаиләсе көч сынашты. Бәйгене башлангыч сыйныфлар укытучысы Бурганова Римма Нурмөхәммәт кызы алып бик күңелле итеп алып барды. Командалар арасында төрле ярышлар үткәрелде: шакмак ташу, плакат ясау, “разведчиклар”, “пингвиннар” һәм башка бик күңелле уеннар.

Командалар үзләренең җитез, актив, өлгер, көчле, креатив булуларын күрсәттеләр. Сыйныф укучылары бик яхшы җанатарлар булдылар. Спортзал бу көнне шау итеп торды. Ярышлар җыр – бию белән үрелеп барды.

Укучылар үз һөнәрләрен күрсәткән арада командалар хәл туплады. Уен ахырында һәр командага грамота һәм истәлекле бүләк тапшырылды. Әниләрне генә түгел, этиләрне дә мәктәп тормышына тарту - бик күркәм гамәл дип саныйм. Киләсе елларда без дә катнашырбыз дип ышанып калам.

**4 нче сыйныф укучысы Харасов Әмир**

## Бердәмлектә көч!



2025 елның 14 февралендә Балтач район мәдәният йортында «Тату сыйныфы серлә-ре» ата-аналар коми-тетлары республика конкурсының зона этабы узды.

Конкурсның максаты-мәктәп укучыларын тәрбияләү мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының һәм ата-аналар комитетларының үзара хезмәттәшлегенең иң яхшы тәҗрибәләрен ачыклау һәм популярлаштыру.

Бәйгенең зона этабында Арча, Саба, Балтач, Кукмара һәм Әтнә муниципаль районнарыннан 5 ата-аналар комитеты катнашты. Безнең команда бәйгедә уңышлы чыгыш ясады. Күәм урта мәктәбенең 5сыйныф укучылары аларның әти әниләре матур чыгыш ясауларын, жюри аерым билгеләп ассызыклады.

Ата-аналар комитетлары аерым этаплардан торган сынауда көч сынаштылар:
1.Визит карточкасы « Безнең күңелле дус сыйныф»;
2.«Тату сыйныф серләре» күргәзмәсе;
3. «Батырлык» иҗади проектын яклау;

Чыгышлар төрле булуга карамастан, алар барысы да бер фикердә иде - ата-аналарның, балаларның һәм мәктәпнең бердәмлеге. Бу бәйгедә катнашу безне тагын да берләштерде.

**Ганиева Л.Ф.,5 нче сыйныф җитәкчесе**



## Китапханәдә кунакта

Без, 2 нче һәм 3нче сыйныф укучылары ,15 нче февральдә авыл китапханәсенә очрашуга бардык. Китапханәче Луиза апа безне патриот шагыйрь М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырды. Без М.Җәлилнең шигырләрен яттан сөйләдек. Алдан ук шигырьләренә иллюстрацияләр ясаган идек. Луиза апа һәрбер укучының эшенә анализ ясады.Соңыннан ул истәлекле бүләкләр тапшырды. Шундый матур һәм эчтәлекле очрашу өчен китапханәче Луиза апага зур рәхмәт.

**3 сыйныф укучысы Хәкимов Риназ**

## Яраткан ел фасылым

Бер көнне уйга баттым әле, нинди ел фасылын яратам соң мин? Кайсын алсаң да, барысы да үзенчә матур. Кыштан башлыйк. Кыш көне салкын, әмма ул нindидер тылсымлы ел фасылы, бар дөнья ап-ак, җем-җем килә бит. Урамда кар атыш уйнап, чана, чаңгы, тимераякта шуып була. Әле Яңа ел бүләкләре. Эх, тәмле дә соң! Әле туган көнем дә кыш көне бит минем. Бүләкләр бирәләр. Кыш артыннан яз килә. Кояш күзне чагылдыра. Дөнья уяна, кошлар сайрый, җир яшелләнә. Җәй ел фасылы, анысы безгә балаларга тагы да якын. Без көтеп алган каникулга чыгабыз. Дәрес карыйсы юк, йокы туя, караңгы төшкәнче урамда чабабыз. Әти белән балыкка, әни белән җиләккә, су коенырга барабыз. Көз ел фасылын тагы сагынып көтеп алабыз, чөнки укырга тизрәк киләсе килә, мәктәпне укытучы апаны сагынабыз. Шулай уйлый торгач, мин шундый фикергә килдем әле, барлык ел фасылы да матур икән бит. Аерым гына сайлап алып булмас шул.

**2 нче сыйныф укучысы Василов Азат**

## Батырлар гел истә

Менә язның 2025 елы килеп җитте,

Көннәр һәркөн үтеп бара.

Кечкенә балалар зур батырлар булып беттеләр,

Безнең илне алар сакларга киттеләр.

**6 нчы сыйныф укучысы Сафиуллин Илнар.**



## Мәктәбебезгә гинеколог килде



27 нче февраль көнне мәктәбебезгә Әтнә район хастаханәсенең акушер-гинекологы Галиуллина Зөһрә Рамил кызы килде. Ул 5-10 нчы сыйныфларда укучы кызлар белән очрашты. Хатын-кызларның җенси органнары гигиенасы, хатын-кызның сәламәтлеген саклау буенча киңәшләр, менструаль цикл дәвамлылыгы турында мәгълүмат бирде. Шулай ук Зөһрә Рамил кызы абортларның сәламәтлек өчен куркыныч булуын медицина күзлегеннән чыгып бик үтемле итеп аңлатты. Укучы кызлар өчен әлеге очрашу бик файдалы булды. Укучылар бу киңәшләргә колак салырлар, сәламәт һәм акыллы булырлар дип ышанып калабыз.

**Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Халикова Г.З.**

## Безнең уңышлар куандыра

26 нчы февраль көнне без, 9 нчы сыйныф укучылары, “Смотр строевой песни” бәйгесендә катнаштык. Ул Әтнә урта мәктәбендә узды. Безнең отряд “Смотр строевой песни” категориясендә 2 нче урын, ә 5 команда арасында 3 нче урын яулады. Без үзебезгә алда да уңышлар телибез.

**9 нчы сыйныф укучысы Сибагатова Илвинә**

## Әлифба бәйрәме



Әле генә бу хәреф “А”, монысы “Б” дип утыра идек, ни арада Әлифбаны укып та бетергәнбез! Ул безнең өчен шундый кызык, шундый кадерле китапка әйләнде. 7 февраль көнне классыбызда узган Әлифба бәйрәмендә аннан аерыласы да килмәде.

Бәйрәмгә без алдан, бик тырышып әзерләндек. Яңа җырлар, шигырьләр өйрәндек. Бәйрәмгә әти-әниләрне чакырдык. Укытучыбыз Гөлназ апа белән бергә аларга һөнәрләребезне күрсәттек. Мәктәп дирекциясе безне котлап дипломнар тапшырды, укытучыбыз да, әти-әниләр дә безгә бүләкләр алганнар – шундый рәхәт булды!

Әлифба белән без әнә шулай саубуллаштык. Әмма күңелсезләнеп торырга вакыт юк, алда безне тагын да кызыклырак, матуррак китаплар, дәреслекләр көтә. Без аларның серенә хәзер тиз төшенербез, чөнки Әлифба безне укырга өйрәтте. Рәхмәт аңа!

**1 сыйныф укучысы Батталов Айрат**